КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 9 июнь г.Казань № 443

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы милкендә булган, өченче затлар хокукларыннан ирекле (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү инфраструктурасын төзи торган оешмаларга бирү өчен күздә тотылган мөлкәт исемлеген формалаштыру, алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару тәртибен раслау турында» 2016 ел, 25 май, 353 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 22 февраль, 114 нче, 2018 ел, 29 сентябрь, 882 нче карарлары белән кертелгән үзхгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карар исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Өченче зат хокукларыннан азат булган ( хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга бирү өчен билгеләнгән Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәт исемлеген булдыру, алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару тәртибен раслау турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Карарга теркәлгән Өченче зат хокукларыннан азат булган ( хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) һәм кече һәм урта

эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга бирү өчен билгеләнгән Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәт исемлеген булдыру, алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару тәртибен расларга (алга таба - исемлек).»;

әлеге карар белән расланган Өченче зат хокукларыннан азат булган (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга бирү өчен билгеләнгән Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәт исемлеген булдыру, алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару тәртибендә:

Тәртипнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Өченче зат хокукларыннан азат булган ( хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга бирү өчен билгеләнгән Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәт исемлеген булдыру, алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару тәртибе»;

1 пунктта «кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм» сүзләреннән соң «, шулай ук шәхси эшмәкәр булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын билгеләү буенча эксперимент уздыру турында» 2018 елның 27 ноябрендәге 422-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән эксперимент үткәрү срогы дәвамында» сүзләрен өстәргә;

2 пунктның «а» пунктчасында «кече һәм урта эшмәкәрлек» сүзләреннән соң «, шәхси эшмәкәр булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга» сүзләрен өстәргә;

3 пунктның беренче абзацына «һәм  шәхси эшмәкәр булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затлар» сүзләрен өстәргә;

6 пунктның беренче абзацына «кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм» сүзләреннән соң «, шулай ук шәхси эшмәкәр булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга» сүзләрен өстәргә;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы милкендә булган, өченче затлар хокукларыннан ирекле (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү инфраструктурасын төзи торган оешмаларга бирү өчен күздә тотылган мөлкәт исемлегенә кертелгән дәүләт мөлкәтен арендага бирү тәртибен һәм шартларын раслау турында» 2016 ел, 23 декабрь, 976 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 15 декабрь, 1146 нчы, 2021 ел, 25 март, 170 нчы  карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы милкендә булган, өченче затлар хокукларыннан ирекле (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) һәм кече һәм урта эшмәкәрлек

субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү инфраструктурасын төзи торган оешмаларга бирү өчен күздә тотылган мөлкәт исемлегенә кертелгән дәүләт мөлкәтен арендага бирү тәртибенә һәм шартларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктта «, шулай ук шәхси эшмәкәр булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын билгеләү буенча эксперимент уздыру турында» 2018 елның 27 ноябрендәге 422-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән эксперимент үткәрү срогы дәвамында» сүзләрен өстәргә;

10 пунктның беренче абзацында «бирелә» сүзеннән соң «шәхси эшмәкәр булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга» сүзләрен өстәргә;

11 пунктта «кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты белән» сүзләрен төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин